**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552)3-44-14,E-mail: Aktanish@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

РАСПОРЯЖЕНИЕ ____________ ПР-42 от 06.03.2024 БОЕРЫК №____

**«Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы капиталь төзелеш идарәсе» муниципаль учреждениесен бетерү турында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындаңы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 5 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль учреждениеләре эшчәнлеген оптимальләштерү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 423740, ТР, Актаныш районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 17 йорт, 19 каб адресы буенча урнашкан «Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы капиталь төзелеш идарәсе» муниципаль учреждениесен (алга таба – Учреждение) бетерергә.

2. Бетерү чараларын үткәрү өчен учреждениенең бетерү комиссиясен түбәндәге составта төзергә:

Зәйнетдинов Булат Рифат улы - бетерү комиссиясе рәисе;
Хузин Рамил Радист улы - бетерү комиссиясе әгъзасы;
Шаехова Ильвира Марс кызы - бетерү комиссиясе әгъзасы.

3. Бетерү комиссиясенә:

– Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) белән учреждение эшләрен бетерү процессында идарә итүгә килешү төзергә (алга таба-килешү) һәм гамәлдәге законнарда каралган учреждениене бетерү буенча барлык кирәкле гамәлләрне башкарырга;

- предприятиене 30.09.2024 елга кадәр бетерергә;

4. Бетерү комиссиясе рәисенә:

- учреждениенең барлык хезмәткәрләренә эштән азат ителү турында хәбәр итәргә, хезмәткәрләргә законнарда каралган гарантияләрне тәэмин итәргә, гамәлдәге законнарда каралган башка бетерү чараларын гамәлгә ашырырга;

- юридик затларны теркәүне гамәлгә ашыручы оешмага учреждение урнашкан урын буенча учреждениене бетерү һәм бетерү комиссиясен билгеләү турында кабул ителгән карар турында хәбәр иткәндә мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы И.Ш.Бариевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.А.Ильясов**